**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2022 елның «12» сентябреннән | № 253

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр төрләрен һәм административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында» 2021 елның 6 маендагы 221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.13 һәм 32.13 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр төрләрен һәм административ җәза үтәлә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында» 2021 елның 6 маендагы 221 номерлы карарының 1 номерлы кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның «12» сентябреннән 253
номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза үтәү өчен эш төрләре

1. Урамнарны, паркларны, скверларны, ял зоналарын һәм ишегалды территорияләрен җыештыру.
2. Паркларны, скверларны, ял зоналарын һәм ишегалды территорияләрен төзекләндерү, санитар чистарту һәм яшелләндерү.
3. Агач һәм бордюрларны агарту.
4. Юл техникасы өчен керү мөмкин булмаган урыннарда юл катламнарын пычрактан һәм кардан чистарту.
5. Пляжларны һәм яр буйларын чистарту.
6. Зират территорияләрен җыештыру.
7. Урман кисү урыннарын бүлү (визирлар кисү, делянка баганалары ясау һәм урнаштыру).
8. Яшь үсентеләрне карау (сирәкләү, чистарту).
9. Урман фонды территорияләрен төзекләндерү, урман кишәрлекләрен санкцияләнмәгән җитештерү һәм куллану калдыкларыннан чистарту, ял итү урыннарын тәртипләү, беседкалар урнаштыру, ауган агачларны җыештыру һ. б.);
10. Урман культуралары җитештерү (кул белән үсентеләр утырту).
11. Автомобиль юлларын, юлларны, тротуарларны, газоннарны чистарту.